РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«12» май 2020 с. Тюлячи № 215

Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген яңадан башлау турында

МКУ «Район Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» 2020 елның 11 маендагы 142 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе территориясендә халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү чараларының гамәлдә булуын озайту турында» 2020 елның 28 апрелендәге 294 номерлы Указы нигезендә яңа короновирус инфекциясе (COVID-19) таралуга бәйле рәвештә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген 2020 елның 12 маеннан яңадан башларга.
2. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә мәгариф оешмалары эшен оештыру буенча тәкъдимнәр җибәрү турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 2020 елның 8 маендагы 02/8900-2020-24 номерлы хаты нигезендә учреждениенең эшен оештырырга.
3. 2020 нче елның 12 нче маеннан Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны карап торган өчен ата-аналар түләве яңадан исәпләнә башлый.
4. МКУ «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» (Карпова Н.В.), МКУ «Теләче муниципаль районының Үзәкләштерелгән бухгалтериясе» (Павлова Л.П.), Теләче муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәргә.
5. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов